## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

### Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

“23” ноябрь 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2024 елның 23 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2025 елда Күәм авыл җирлеге Күәм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен яктырткычлар, проводлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү);

-Торак пункт территориясен төзекләндерү (газон чапкыч сатып алу, Күәм авылы территориясен чистарту (агачларны, куакларны кисү) эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү (Күәм авылының Космодемьянская урамындагы чишмәне ремонтлау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыенының беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 546 (биш йөз кырык алты) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 283 (ике йөз сиксән өч) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 272 (ике йөз җитмеш ике) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 11 (унбер) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2025 елда Күәм авыл җирлеге Күәм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар

һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен яктырткычлар, проводлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү);

-Торак пункт территориясен төзекләндерү (газон чапкыч сатып алу, Күәм авылы территориясен чистарту (агачларны, куакларны кисү) эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү (Күәм авылының Космодемьянская урамындагы чишмәне ремонтлау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Хасбиуллин И.И.